**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**2022 елның 23 декабре** **109-РС номер**

# КАРАР

**«Лаеш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен бирү тәртибе хакындагы нигезләмәне раслау турында» 2015 елның 27 апрелендәге 17-РС номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы «Дәүләт Вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында» 2012 елның 03 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында карар чыгарды:

1. Лаеш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм бу мәгълүматларны бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълүмат чараларына бирү тәртибе турында Лаеш муниципаль районы Советының 2015 елның 27 апрелендәге 17-РС номерлы карары (2016 елның 19 февралендәге 10-РС номерлы соңгы үзгәрешләр белән) белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның " г " пунктчасын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«г) җир кишәрлеге, күчемсез милекнең башка объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (катнашу өлешләре, оешмаларның устав (туплау) капиталында пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу (мондый килешүләрнең гомуми суммасы (мондый килешүләрнең суммасы) вазыйфаи затның һәм аның хатынының (иренең) гомуми кеременнән артып китсә, акчаларны алу чыганаклары турында соңгы өч ел өчен белешмәләр хисап чорына кадәр.»».

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районы Советы аппараты Җитәкчесе А. Ә. Нурмөхәммәтовка йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы Рәисе** **И.Ф. Зарипов**